| ГЛАВА<br>ЦИПЬИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЧЕПЬЯ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» сентябрь 2019 ел № 18

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының коллегиаль утырышларында гражданнарның катнашуын тәэмин итү тәртибен раслау турында.**

09.02.2009 № 8-ФЗ "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында" федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, Чепья авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының коллегиаль органнары утырышларында гражданнарның катнашуын тәэмин итү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати- телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемә алам.

Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин